ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРАКЧЫ
АВЫЛ ЖИРЛГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422661, Балык Бистәсе районы,
Уракчы авылы,
Совет урамы, 36А

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УРАХЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422661, Рыбно-Слободский район,
село Урахча,
улица Советская, 36А

тел.(факс): (884361) 2-94-35, электронная почта: Urah.Rs@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 14 2021 елның 14 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында”гы Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2017 елның 3 июлендәге 277-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Уракчы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 26 апрелендәге 7 номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге территориясендә Төзекләндерү кагыйдәләре таләпләрен үтәү буенча муниципаль контрольне гамәлгә ашыру буенча административ регламентны раслау турында”гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 1.8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

"1.8. Төзекләндерү (уңайлылык булдыру) өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәләре.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып юридик затны, шәхси эшкуарны, гражданны тикшерү актын төзү тора.

Тикшерү акты ул төгәлләнгәннән соң ук турыдан-туры ике нөсхәдә рәсмиләштерелә, аларның берсе кушымталарның күчермәләре белән муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затка, аның вәкаләтле вәкиленә танышу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында расламa алып тапшырыла.

Физик зат, җитәкче, башка вазыйфаи зат яисә юридик затның вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелүче зат акт белән танышу турында яисә тикшерү акты белән танышуны кире кагу турында расламa бирүдән баш тарткан очракта, акт заказлы почта белән тапшыру турындагы хәбәрнамә белән юллана, ул муниципаль контроль органы эшендә саклanучы тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә үзара багланышны гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда тикшерү акты җитәкчегә, башка вазыйфаи затка яисә юридик затның вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә тикшерелә торган затка әлеге документны алуны раслауны тәэмин итүче ысул белән җибәрелгән акт тикшерелүче зат тарафыннан алынган дип санала.

Тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләр, сынаулар, махсус тикшерүләр, экспертизалар нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр алырга кирәк булган очракта, тикшерү акты контроль буенча чаралар төгәлләнгәннән соң өч эш көненнән артмаган срокта төзелә һәм муниципаль контроль гамәлгә ашырыла торган затларга, аларның вәкаләтле вәкилләренә расламa алып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша һәм (яисә) әлеге актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон култамгасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә үзара багланышны гамәлгә ашыруга ризалыгы булганда) күрсәтелгән документны алуны раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрелә.

Бу чакта күрсәтелгән документны алу турында хәбәрнамә һәм (яисә) бүтән раслау муниципаль контроль органы эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә.".

1.2) 3.3 пунктындагы 11 абзацны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уракчы авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Уракчы авылы, Совет ур., 36А йорт; Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Мельничный

Пүчинкәсе авылы, Киров ур., 20 Б йорт, шулай ук http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Уракчы авыл җирлеге
Башлыгы Ф.М. Гәрәев